РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 25 марты Кукмара ш. № 113

Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү турында Нигезләмә

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә, муниципаль хезмәтнең нәтиҗәлелеген тәэмин итү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри дәрәҗәсен күтәрү максатларында Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү турында Нигезләмәне расларга (кушып бирелә).
2. «Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү турында Нигезләмә хакында» Кукмара район Советының 2008 елның 11 июлендәге 40 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев

Кукмара муниципаль район Советының
2022 елның 25 мартындагы 113 номерлы
карарына кушымта

**Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү турында НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Әлеге нигезләмә белән Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү тәртибе билгеләнә.

2. Аттестация муниципаль хезмәткәрнең биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килүен билгеләү максатларында, аның һөнәри эшчәнлеген бәяләү нигезендә үткәрелә.

Аттестация муниципаль хезмәтнең кадрлар составын формалаштыруга, муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри дәрәҗәсен күтәрүгә, җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфаларын кыскартканда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә өстенлекле хокукны билгеләүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итүгә, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартларын үзгәртүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән.

3. Түбәндәге муниципаль хезмәткәрләр аттестацияләнергә тиеш түгел:

а) биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасында бер елдан ким эшләгәннәр;

б) 60 яшькә җиткәннәр;

в) йөкле хатын-кызлар;

г) йөклелек һәм бала табу буенча отпускта һәм өч яше тулганчыга кадәр бала карау буенча отпускта булганнар. Күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрләрне ялдан чыкканнан соң кимендә бер елдан соң гына аттестацияләү мөмкин;

д) кыска сроклы хезмәт килешүе (контракт) нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар.

4. Муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү өч елга бер тапкыр үткәрелә.

## II. АТТЕСТАЦИЯ ҮТКӘРҮНЕ ОЕШТЫРУ

5. Муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү өчен, Кукмара муниципаль районы Советы карары белән Кукмара муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясе (алга таба – аттестация комиссиясе) оештырыла.

6. Аттестация комиссиясе составына Кукмара муниципаль районы Башлыгы урынбасары, муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән муниципаль хезмәт һәм кадрлар, хокукый бүлекчә һәм бүлекчә мәсьәләләре буенча бүлекчәдән), шулай ук муниципаль хезмәт белән бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез эксперт-белгечләр сыйфатында, экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә чакырыла торган фәнни һәм мәгариф учреждениеләре, башка оешмалар вәкилләре дә керә. Бәйсез экспертлар саны аттестация комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче, вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматлардан файдалану белән бәйле муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү өчен, аттестация комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

Аттестация комиссиясе составы аттестация комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыклары барлыкка килү мөмкинлеге булмаслык итеп төзелә.

7. Аттестация комиссиясе комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзаларыннан тора. Аттестация комиссиясенең барлык әгъзалары да карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия.

8. Муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү өчен, Кукмара муниципаль районы Башлыгы карары буенча түбәндәге нигезләмәләрдән торган хокукый акт чыгарыла:

а) аттестация үткәрү графигын раслау турында;

б) аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәрләр исемлеген төзү турында;

в) аттестация комиссиясе эше өчен кирәкле документларны әзерләү турында.

9. Аттестация үткәрү графигында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) аттестация үткәрелә торган җирле үзидарә органы, бүлекчәнең атамасы;

б) аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәрләр исемлеге;

в) аттестацияне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

г) җирле үзидарә органының тиешле бүлекчәләренең аларны тапшыру өчен җаваплы җитәкчеләрне күрсәтеп, аттестация комиссиясенә кирәкле документларны тапшыру датасы.

10. Аттестация башланганчы ике атнадан да соңга калмыйча, аттестация комиссиясенә аттестация чоры өчен аттестация узарга тиешле муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын башкаруы турында аның турыдан-туры җитәкчесе кул куйган һәм югары җитәкче раслаган бәяләмә тапшырыла.

11. Әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында каралган бәяләмәдә муниципаль хезмәткәр турында түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

б) аттестация уздыру вакытына биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы һәм әлеге вазыйфага билгеләнү датасы;

в) хәл итүдә (эшләүдә) муниципаль хезмәткәр катнашкан төп мәсьәләләр (документлар) исемлеге;

г) муниципаль хезмәткәрнең һөнәри, шәхси сыйфатларына һәм һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләренә дәлилләнгән бәя.

12. Аттестация чоры өчен аттестация узарга тиешле муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын башкаруы турында бәяләмәгә күрсәтелгән чорга муниципаль хезмәткәр башкарган йөкләмәләр турында һәм үзе әзерләгән документларның проектлары турында муниципаль хезмәткәрнең һөнәри эшчәнлеге турында еллык хисапларда булган белешмәләр кушымта итеп бирелә.

Һәр аттестация узган саен, аттестация комиссиясенә муниципаль хезмәткәрнең алдагы аттестация күрсәткечләре белән аттестация кәгазе тапшырыла.

13. Кукмара муниципаль районы Советының муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлек аттестация башланганчы кимендә бер атна элек аттестация үтүче һәр муниципаль хезмәткәрне аттестация чорында үзләренең вазыйфаи бурычларын үтәүләре турында тәкъдим ителгән бәяләмә белән таныштырырга тиеш. Шул ук вакытта аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәр аттестация комиссиясенә күрсәтелгән чорда үзенең һөнәри эшчәнлеге турында өстәмә белешмәләр, шулай ук тәкъдим ителгән бәяләмә белән килешмәве турында гариза яисә турыдан-туры җитәкчесенең бәяләмәсе белән килешмәве турында аңлатма язуы тапшырырга хокуклы.

## III. АТТЕСТАЦИЯ ҮТКӘРҮ

14. Аттестация аттестация комиссиясе утырышына аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрне чакырып үткәрелә. Муниципаль хезмәткәр әлеге комиссия утырышына җитди сәбәпсез килмәгән яисә аттестациядән баш тарткан очракта, муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт турындагы законнар нигезендә дисциплинар җаваплылыкка тартыла, ә аттестация соңрак вакытка күчерелә.

Аттестация комиссиясе тәкъдим ителгән документларны карый, аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрнең, ә кирәк очракта – аның турыдан-туры җитәкчесенең муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге турында хәбәрләрен тыңлый. Аттестацияне объектив үткәрү максатыннан, аттестация чоры өчен аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырылган үзенең һөнәри эшчәнлеге турында өстәмә мәгълүматларны караганнан соң, аттестация комиссиясе аттестацияне комиссиянең киләсе утырышына күчерергә хокуклы.

15. Муниципаль хезмәткәрнең һөнәри эшчәнлегенә карата һөнәри һәм шәхси сыйфатлары турында фикер алышу объектив һәм яхшы мөнәсәбәттә булырга тиеш.

Муниципаль хезмәткәрнең һөнәри эшчәнлеге аның биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча квалификация таләпләренә туры килүен билгеләү, аның тиешле бүлекчә (җирле үзидарә органы) алдында куелган бурычларны хәл итүдә катнашуы, ул башкара торган эшнең катлаулылыгы, аның эффектлылыгы һәм нәтиҗәлелеге нигезендә бәяләнә.

Шул ук вакытта муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясен үтәү нәтиҗәләре, муниципаль хезмәткәрнең һөнәри белемнәре һәм эш тәҗрибәсе, муниципаль хезмәткәрләрнең чикләүләрне үтәве, тыюлар бозу булмау, муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән таләпләрнең һәм йөкләмәләрнең үтәлүе, шулай ук башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү вакытында, шулай ук оештыру сәләте исәпкә алынырга тиеш.

16. Аттестация комиссиясе утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

17. Аттестация комиссиясе карары, аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәр һәм аның турыдан-туры җитәкчесе булмаганда, утырышта катнашучы аттестация комиссиясе әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш

бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, муниципаль хезмәткәр биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә дип танылa.

Аттестация комиссиясе әгъзасы булган муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү чорында аның әлеге комиссиядә әгъзалыгы туктатылып торыла.

18. Муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү нәтиҗәләре буенча аттестация комиссиясе тарафыннан түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә;

б) биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә һәм, билгеләнгән тәртиптә вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә кадрлар резервына вазыйфаи үсеш тәртибендә кертүгә тәкъдим ителә;

в) һөнәри яңадан әзерләү яки квалификация күтәрүне уңышлы узган очракта, биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә;

а) биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килми;

19. Аттестация нәтиҗәләре аттестацияләнгән муниципаль хезмәткәрләргә тавыш бирүгә йомгак ясаганнан соң хәбәр ителә.

Аттестация нәтиҗәләре муниципаль хезмәткәрнең кушымта нигезендә форма буенча төзелгән аттестация кәгазенә кертелә. Аттестация кәгазенә утырышта катнашкан аттестация комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретарь һәм аттестация комиссиясе әгъзалары кул куя.

Муниципаль хезмәткәр аттестация кәгазе белән кул куеп таныша.

Аттестация узган муниципаль хезмәткәрнең аттестация кәгазе һәм аның аттестация чорында вазыйфаи бурычларын үтәү турындагы бәяләмәсе муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшендә саклана.

Аттестация комиссиясе секретаре комиссия утырышы беркетмәсен алып бара, анда утырыш карарын һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен терки. Аттестация комиссиясе утырышы беркетмәсенә утырышта катнашкан аттестация комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретарь һәм аттестация комиссиясе әгъзалары кул куя.

20. Муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү материаллары Кукмара муниципаль районы Башлыгына аны үткәргәннән соң җиде көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

21. Аттестация уздырганнан соң бер ай эчендә аның нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органының хокукый акты чыгарыла яисә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең муниципаль хезмәткәр турында түбәндәге карары кабул ителә:

а) вазыйфаи үсеш тәртибендә вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен кадрлар резервына билгеләнгән тәртиптә кертелергә тиеш;

б) яңадан һөнәри әзерләүгә яки квалификация күтәрүгә җибәрелә;

в) муниципаль хезмәт вазыйфасында түбән төшерелә.

22. Муниципаль хезмәткәр яңадан һөнәри әзерләүдән, квалификация күтәрүдән яисә башка муниципаль хезмәт вазыйфасына күчерүдән баш тарткан очракта, яллаучы (эш бирүче) вәкиле муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәт турындагы законнар нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат итәргә һәм аны муниципаль хезмәттән чыгарырга хокуклы.

Аттестация үткәрелгәннән соң бер ай узгач, әлеге аттестация нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәткәрне башка муниципаль хезмәт вазыйфасына күчерү йә аны муниципаль хезмәттән азат итү рөхсәт ителми. Муниципаль

хезмәткәрнең авырган һәм ел саен түләнә торган отпуск вакыты билгеләнгән вакытка исәпләнми.

23. Муниципаль хезмәткәр аттестация нәтиҗәләренә Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү турында Нигезләмә кушымта

# МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРНЕҢ АТТЕСТАЦИЯ КӘГАЗЕ

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) _______________________________________
_______________________________________________________________________________
2. Туган елы, көне, ае ________________________________________________
_______________________________________________________________________________
3. Һөнәри белем, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исеме булу-булмау турында мәгълүмат
________________________________________________________________________
(кайчан һәм нинди уку йорты тәмамлаган,
_______________________________________________________________________________
белеме буенча белгечлеге һәм квалификациясе,
_______________________________________________________________________________
гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме)
4. Аттестация вакытына биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы
һәм бу вазыйфага билгеләнү датасы ____________________________________________________
_______________________________________________________________________________
5. Муниципаль хезмәт стажы (шул исәптән, дәүләт граждан хезмәте стажы)
______________________________________________________________________
6. Гомуми хезмәт стажы _________________________________________________________
7. Муниципаль хезмәткәргә сораулар һәм аларга кыскача җаваплар ________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
8. Аттестация комиссиясе тарафыннан әйтелгән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
9. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан алдагы киңәшләрне үтәүгә кыскача бәя
___________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
(үтәлгән, өлешчә үтәлгән, үтәлмәгән)
10. Аттестация комиссиясе карары __________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
(биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә;биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә, билгеләнгән тәртиптә вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә кадрлар резервына вазыйфаи үсеш тәртибендә кертүгә тәкъдим ителә; һөнәри яңадан әзерләү яки квалификация күтәрүне уңышлы узган очракта, биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә; биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килми
11. Аттестация комиссиясенең сан ягыннан составы ____________________________
Утырышта аттестация комиссиясенең __________________ әгъзасы катнашты.
Тавышлар саны: риза _________________________, каршы _______________________.
12. Искәрмәләр _______________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

Аттестация комиссиясе рәисе ____________________ _______________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)
Аттестация комиссиясе рәисе
урынбасары ____________________ _______________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)
Аттестация комиссиясе секретаре ____________________ _______________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)
Аттестация комиссиясе әгъзалары ____________________ _______________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)
Аттестация үткәрү датасы
__________________________
Аттестация кәгазе белән таныштым __________________________________________
_______________________________________________________________________________
(муниципаль хезмәткәр имзасы, дата)
Җирле үзидарә органы мөһере урыны